**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"16" ноябрь 2024 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә ту Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Мәрҗән авылы территориясен яхшырту (территорияне чистарту - Мәрҗән авылындагы үләннәрне чабу).
- Ремонт, коймалар кую, традицион күмелгән урыннарны төзекләндерү (Мәрҗән авылындагы зират территориясен чистарту (үлән чабу, агач кисү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Мәрҗән авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Мәрҗән авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Ф.Т.Гатауллин

СОВЕТ КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1610000733